**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**2006 елның 22 февралендәге 68 номерлы**
**КАРАР**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Үзгәрешләр кертелгән документлар исемлеге
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 21 апрелендәге 204 номерлы, 2006 елның 15 июнендәге 307 номерлы, 2006 елның 10 июлендәге 348 номерлы, 2007 елның 20 апрелендәге 136 номерлы, 2007 елның 26 сентябрендәге 510 номерлы, 2007 елның 27 сентябрендәге 514 номерлы, 2008 елның 22 февралендәге 108 номерлы, 2008 елның 7 ноябрендәге 782 номерлы, 2008 елның 31 декабрендәге 941 номерлы, 2010 елның 29 гыйнварындагы 43 номерлы, 2010 елның 26 июлендәге 587 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге 811 номерлы, 2010 елның 17 декабрендәге 1078 номерлы, 2011 елның 10 февралендәге 81 номерлы, 2011 елның 24 августындагы 695 номерлы, 2011 елның 18 октябрендәге 865 номерлы, 2012 елның 21 апрелендәге 317 номерлы, 2012 елның 8 ноябрендәге 973 номерлы, 2013 елның 2 февралендәге 69 номерлы, 2013 елның 24 июнендәге 436 номерлы, 2013 елның 7 ноябрендәге 861 номерлы, 2014 елның 17 гыйнварындагы 21 номерлы, 2014 елның 20 июнендәге 426 номерлы, 2016 елның 20 февралендәге 103 номерлы,2016 елның 6 августындагы 536 номерлы, 2017 елның 15 июлендәге 497 номерлы, 2017 елның 28 ноябрендәге 920 номерлы, 2017 елның 28 декабрендәге 1070 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге 1126 номерлы, 2018 елның 12 маендагы 350 номерлы, 2018 елның 18 маендагы 375 номерлы, 2018 елның 24 июлендәге 592 номерлы, 2018 елның 8 сентябрендәге 762 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 1127 номерлы, 2019 елның 19 апрелендәге 311 номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 1192 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 94 номерлы, 2020 елның 17 мартындагы 196 номерлы, 2020 елның 27 маендагы 429 номерлы, 2020 елның 28 июлендәге 629 номерлы, 2020 елның 2 октябрендәге 902 номерлы, 2020 елның 6 ноябрендәге 1000 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 1259 номерлы, 2021 елның 3 февралендәге 48 номерлы карарлары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм аның структурасы турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) хезмәткәрләренең чик санын вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 14 423,34 мең сум айлык хезмәт хакы фонды белән 908,5 берәмлек күләмендә билгеләргә, шул исәптән:

122 берәмлек - Министрлык аппараты хезмәткәрләре вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 2 471,367 мең сум айлык хезмәт хакы фонды белән;

786,5 берәмлек - Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләре вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 11 951,974 мең сум айлык хезмәт хакы фонды белән.

3. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына министрның өч урынбасарын, шул исәптән бер беренче урынбасарын булдырырга рөхсәт итәргә.

4. Үз көчен югалтты. – (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 10 июлендәге 348 номерлы карары).

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2001 елның 9 июлендәге 425 номерлы карарының 1, 2, 3, 6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 елның 22 февралендәге
68 номерлы карары
белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

Үзгәрешләр кертелгән документлар исемлеге
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 февралендәге 103 номерлы, 2016 елның 6 августындагы 536 номерлы, 2017 елның 15 июлендәге 497 номерлы, 2017 елның 28 ноябрендәге 920 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге 1126 номерлы, 2018 елның 12 маендагы 350 номерлы, 2018 елның 18 маендагы 375 номерлы, 2018 елның 8 сентябрендәге 762 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 1127 номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 1192 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 94 номерлы, 2020 елның 27 маендагы 429 номерлы, 2020 елның 28 июлендәге 629 номерлы карарлары редакциясендә)

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләүне, шәхес һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне, хокук мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыруны, җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне һәм Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүне гамәлгә ашыручы башкарма органы булып тора.

Министрлык Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы булып тора.

Министрлык үз вәкаләтләрен тормышка ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча өстенлекле максатларны һәм бурычларны тәэмин итә.

1.2. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Рос-

сия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Министрлык үз эшчәнлеген башкарма хакимиятнең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара бәйләнештә алып бара.

1.4. Министрлык юридик зат булып тора, мөстәкыйль баланска, банк оешмаларында законнар нигезендә ачыла торган исәп-хисап һәм башка счетларга, үз исеме һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән мөһергә, башка мөһерләргә, билгеләнгән үрнәктәге штамплар һәм бланкларга ия.

1.5. Министрлыкның урнашкан урыны - Казан шәһәре, Кремль ур., 16.

## II. Министрлыкның төп бурычлары

2.1. Министрлыкның төп бурычлары булып тора:

2.2.1. Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр һәм Татарстан Республикасы үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.

2.2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының шәхес һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итүче нормалар иҗат итү эшчәнлеге дәрәҗәсенә ирешү.

2.2.3. Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать судьялары эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү.

2.2.4. Гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын гамәлгә ашыру.

2.2.5. Хокук мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.

2.2.6. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм оешмалар тарафыннан муниципаль норматив хокукый актлар турында мәгълүмат ала алсын өчен шартлар тудыру.

## III. Министрлыкфункцияләре

3.1. Министрлык төп функцияне - юстиция өлкәсендә идарә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы (02.03 <*>);

3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән (01.02 <*>);

түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы мәгълнматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән:

цифрлаштыру белән идарә (01.15 <*>);

элемтә белән идарә(03.04 <*>);

гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш

хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән (02.01 <*>);

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән (01.07 <*>);

социаль-икътисадый программалаштыру функцияләрен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән (01.01 <*>);

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән (03.05.04 <*>);

архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән (01.17 <*>).

--------------------------------

<*>Кодны «Татарстан РеспубликасыМинистрларКабинетының «Татарстан РеспубликасыбашкармахакимиятеорганнарыфункцияләреКодификаторынраслаутурында» 2006 елның 02 маендагы 220 номерлыкарарыбеләнрасланган Татарстан Республикасыбашкармахакимиятеорганнарыфункцияләре Кодификаторы буенчатамгалау

## IV. Министлык вәкаләтләре

4.1. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә әлеге Нигезләмәнең III бүлеге нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

4.1.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының закон чыгару һәм башка нормалар иҗат итү эшчәнлеген координацияләнгне гамәлгә ашыра.

4.1.2. Россия Федерациясеһәм Россия Федерациясесубъектларыныңуртаккарамагындагымәсьәләләрбуенчафедеральзаконнарпроектларына, Татарстан Республикасызаконнарыпроектларына, Татарстан Республикасы Президенты указларыпроектларына, Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинеты карарларыпроектларына, шулайукТатарстанРеспубликасыПрезидентынаимзалауөченкергән Татарстан Республикасызаконнарынахокукый экспертиза уткәрә.

4.1.3. Законнар һәм башка норматив хокукый актларга экспертиза үткәрнг, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә башка мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә белгечләр һәм экспертларны, дәүләт органнары һәм оешмаларын, фәнни һәм башка оешмалар хезмәткәрләрен җәлеп итә, шул исәптән шартнамә нигезендә дә.

4.1.4. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына

билгеләнгән тәртиптә коррупциягә каршы экспертизаны гамәлгә ашыра.

4.1.5. Эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра.

4.1.6. Үз вәкаләтләре чикләрендә нормалар иҗат итү һәм (яки) хокук куллану эшчәнлегендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрә.

4.1.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәнләт хакимияте башкарма органнарының законнарга туры килми торган норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану турында тиешле карарны нигезләп һәм аның проекты белән берлектә тәкъдимнәр кертә.

4.1.8. Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашыру эшен оештыра һәм координацияли.

4.1.9. Ел саен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингы планы проектына тәкъдимнәр һәм мониторинг нәтиҗәләре турында доклад тәкъдим итә.

4.1.10. Үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән гавами-хокукый характердагы килешүләр, килешүләр һәм башка актлар реестрын алып бара.

4.1.11. Татарстан РеспубликасыМинистрларКабинетына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы законнары проектларын татар теленә тәрҗемә итүне гамәлгә ашыра.

4.1.12. Хокукый мәсьәләләр буенча ведомствоара координацияләү комитеты эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4.1.13. Ел саен Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында хисап бирә.

4.1.14. «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы» нда (www.pravo.gov.ru) урнаштыру өчен Россия Федерациясе федераль сак хезмәтенә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка хокукый актларының электрон үрнәкләрен бирүне тәэмин итә.

4.1.15. Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Президенты актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумының норматив характердагы актларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarsta№.ru) рәсми бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра.

4.1.16. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алуны һәм аларны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarsta№.ru) рәсми бастырып чыгаруны

гамәлгә ашыра.

4.1.17. Үз көчен югалтты. –(ТР Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 ноябрендәге 920 номерлы карары).

4.1.18. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә вәкаләтле органнарның (оешмаларның) «Татарстан Республикасының атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турындагы ходатайстволарын карый һәм тиешле бәяләмәләр әзерли.

4.1.19. Үз көченюгалтты. – (Татарстан РеспубликасыМинистрларКабинетының 2016 елның 6 августындагы 536 номерлыкарары).

4.1.20. Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм торак пунктлар реестрын алып баруны гамәлгә ашыра.

4.1.21. Аларның эшчәнлегенә хокукый ярдәм күрсәтү максатларында җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыра.

4.1.22. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыруны һәм алып баруны һәм аннан белешмәләр бирүне гамәлгә ашыра.

4.1.23. Законнарда билгеләнгән очракларда тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлешен контрольдә тота.

4.1.24. Җирле үзидарә органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә документлар һәм мәгълүмат соратып ала.

4.1.25. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына оештыру-методик ярдәм күрсәтә.

4.1.26. Муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре буенча иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар буенча җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус бирелгән яисә җайлаштырылган урыннар билгели.

4.1.27. Гавами чаралар үткәрүгә бәйле башка вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

4.1.27[1]. Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының (алга таба - депутатлар) сайлаучылар белән очрашулар үткәрүләре өчен, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тәкъдиме буенча - депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан бирелә торган урыннар исемлеген, шулай ук күрсәтелгән биналарны бирү тәртибен билгели.

4.1.28. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук аның балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр, иҗтимагый берләшмәләр, дини

оешмалар, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен профилактикалау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә.

4.1.29. Юридик затларга аларның исемнәрендә Татарстан Республикасының рәсми атамаларын куллануга рөхсәт бирә.

4.1.30. Халыкка хокукый белем һәм хокукый мәгълүмат бирүдә катнаша.

4.1.31. Гражданнарга Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча законнар нигезендә хокукый консультация рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

4.1.32. Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча ведомствоара комиссия төзи.

4.1.33. Законнар җыентыгын әзерләү һәм яңарту, аны бастырып чыгару эшчәнлеген оештыра һәм матди-техник яктан тәэмин итә.

4.1.34. Татарстан Республикасы бюджетыннан Министрлыкны карап тоту һәм Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен каралган акчаларны баш бүлүче һәм алучы функцияләрен гамәлгә ашыра.

4.1.34[1]. Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары сала торган штрафлар буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы булып тора.

4.1.35. Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд департаментының Татарстан Республикасы идарәсе белән берлектә җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4.1.36. Җәмәгать судьялары аппаратларын кадрлар белән тәэмин итүне, җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүне гамәлгә ашыра, аларны яңадан әзерләүне һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыра.

4.1.37. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле биналар (бүлмәләр) бирүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тота.

4.1.38. Җәмәгать судьялары һәм җәмәгать судьялары аппаратлары эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән мөлкәтнең максатчан кулланылышын контрольдә тота.

4.1.39. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары эшен оештыруны тикшерә.

4.1.40. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының структурасын һәм штат расписаниесен үзгәртү (раслау) турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә.

4.1.41. Министрлык аппараты һәм җәмәгать судьялары аппаратлары эшчәнлегендә заманча мәгълүмати технологияләр кертүне һәм куллануны тәэмин итә.

4.1.42. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә заказлар урнаштыра һәм Министрлык ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр

башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары төзи.

4.1.43. Мобилизация эше буенча чараларның үтәлешен оештыра.

4.1.44. Министрлыкны, эшчәнлеге Министрлык эшчәнлеге белән бәйле булган яки аның карамагында булган оешмаларны мобилизацион әзерләүне һәм мобилизацияләүне оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук әлеге чараларны методик яктан тәэмин итә.

4.1.45. Үз компетенциясе кысаларында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.

4.1.46. Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча республика ведомствоара комиссиясе эшендә ярдәм күрсәтә.

4.1.47. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле мәгълүматны, документлар һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып ала.

4.1.48. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, Министрлыкның норматив хокукый актларын, рәсми белдерүләрне бастырып чыгару, Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча башка материалларны урнаштыру өчен басма массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куя.

4.1.49. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә чараларын гамәлгә ашыра.

4.1.49[1]. Терроризмга каршы тору чараларын тормышка ашырганда өйрәнүләр үткәрүдә катнаша.

4.1.49[2]. Министрлыкка беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы әзерлегенә карата таләпләрне үтәүне оештыра һәм тәэмин итә.

4.1.49[3]. «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2.2 пунктының 1 пунктчасында каралган коммерциячел булмаган социаль юнәлешле оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүне һәм коммерциячел булмаган социаль юнәлешле оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне гамәлгә ашыра.

4.1.49[4]. Ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыра.

4.1.50. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## V. Министрлык эшчәнлеген оештыру

5.1. Министрлыкны Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган министр җитәкли.

5.2. Министр Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү һәм билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өчен шәхси җаваплылыкка ия.

5.3. Министр урынбасарларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган бер беренче урынбасарга ия.

5.4. Министр:

5.4.1. Үзенә йөкләнгән эшчәнлек өлкәсе белән бердәм башлангыч нигезендә җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

5.4.2. Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрне раслый.

5.4.3. Үз урынбасарларының вәкаләтләрен билгели, алар арасында вазыйфаларны бүлә, шулай ук Министрлык компетенциясенә караган оператив, оештыру-штат, кадрлар, финанс һәм башка мәсьәләләрне хәл итү буенча Министрлыкның башка вазыйфаи затларының вәкаләтләрен билгели.

5.4.4. Хезмәткәрләрнең билгеләнгән саны һәм хезмәткә түләү фонды кысаларында Министрлыкның штат расписаниесен, шулай ук бүлеп бирелгән ассигнованиеләр кысаларында Министрлык аппаратын тотуга бюджет сметасын раслый, аның үтәлешен контрольдә тота.

5.4.5. Министрлык компетенциясе кысаларында чыгарылган боерыкларны имзалый, аларның үтәлешен контрольдә тота.

5.4.6. Министрлык хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларга кызыксындыру чараларын куллана, законнар нигезендә дисциплинар һәм башка җаваплылыкка тарта.

5.4.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар проектларын, шулай ук юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кертә.

5.4.8. Үз компетенциясе кысаларында Министрлык хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләрен аларга классы чиннар (законнарда билгеләнгән тәртиптә классы чиннар бирә), дәүләт бүләкләре, мактаулы исемнәр бирүгә тәкъдим итә.

5.4.9. Законнарда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.5. Министрлык эшчәнлегенең аеруча мөһим мәсьәләләре Министрлык коллегиясе утырышларында карала.

5.6. Коллегия составы һәм андагы кешеләр саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5.7. Министрлыкта координацияләү, киңәшмә һәм фәнни-методик органнар (советлар, комиссияләр, төркемнәр) төзелергә мөмкин. Бу органнарның составлары

һәм алар турында нигезләмәләр министр тарафыннан раслана.

5.8. Министрлыкны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5.9. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге 68 номерлы карары белән расланган

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ СТРУКТУРАСЫ**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Финанс бүлеге | Министр | | Министр ярдәмчесе |
| Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге | | | |
| Министрның беренче урынбасары | Министр урынбасары | Министр урынбасары | Эшләр белән идарә итүче |
| Хокукый экспертиза һәм нормалар иҗат итү бүлеге | Җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге | Җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге | Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге |
| Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге | Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру һәм хокукый тәэмин итү бүлеге | Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлеге | |
| Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге | Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге | Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлеге | |
| | Татарстан Республикасы Җәмәгать судьялары аппаратлары | Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшч әнлеген тәэмин итү бүлекчәсе | |